**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
**Әлки**
**муниципаль районы**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИСЫ**
**Әлки**
**муниципаль районы**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Адресы: 422870, РТ, Базарлы Матак авылы, Крайнов ур., 56
тел: тел: 8 (84346) 2-17-60

Адрес: 422870, РТ, с.Базарные Матаки, ул. Крайнова, 56
факс: 8 (84346) 2-17-60

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

*2018 елның 17 феврале* *63№*

Әлки муниципаль районында социаль өлкәдә шчәнлек алып баручы социаль юнәлешле коммерциясез оешмаларның нәтиҗәлелеген бәяләү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 елның 13 июлендәге «Социаль өлкәдә эшчәнлек алып баручы социаль юнәлешле коммерциясез оешмалар эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген бәяләү турында» 485 номерлы карары нигезендә социаль өлкәдә эшчәнлек алып баручы социаль юнәлешле коммерциясез оешмаларның халыкка социаль хезмәтләр күрсәтүгә юнәлдерелгән тиешле максатчан программаларны гамәлгә ашыруга бүлеп бирелә торган бюджет чараларыннан файдалануын тәэмин итү, шулай ук күрсәтелә торган социаль хезмәтләрнең сыйфатын арттыру максатында Әлки муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. Социаль өлкәдә эшчәнлек алып баручы социаль юнәлешле коммерциясез оешмаларның (алга таба - Тәртип) нәтиҗәлелеген бәяләү тәртибен расларга.

2. Әлки муниципаль районында социаль өлкәдә эшчәнлек алып баручы социаль юнәлешле коммерциясез оешмаларның нәтиҗәлелеген бәяләүне уздыру өчен җаваплы итеп
Әлки муниципаль районы Башкарма комитетының икътисад бүлеге начальнигы Л.Н. Давыдованы билгеләргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Әлки муниципаль районы
Башкарма комитет җитәкчесе: И.В. Юсупов

Әлки муниципаль районында социаль өлкәдә эшчәнлек алып баручы социаль юнәлешле коммерциясез оешмаларның нәтиҗәлелеген бәяләү тәртибе

1. Әлеге Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районында социаль өлкәдә эшчәнлек алып баручы социаль юнәлешле коммерциясез оешмаларның нәтиҗәлелеген бәяләү тәртибе (алга таба - Тәртип) халыкка социаль хезмәтләр күрсәтүгә юнәлдерелгән максатчан программалар кысаларында бюджет акчалары хисабына эшчәнлекнең нәтиҗәлелеген бәяләү кагыйдәләрен билгели.

2. Әлеге Тәртип максатларында төшенчәләр кулланыла:

социаль юнәлешле коммерциясез оешмалар -1996 елның 12 гыйнварындагы «Коммерциясез оешмалар турында» 7-ФЗ номерлы Федераль законда каралган рәвешләрдә (дәүләт корпорацияләреннән, дәүләт компанияләреннән, сәяси партияләр булган иҗтимагый берләшмәләрдән тыш) төзелгән һәм социаль проблемаларны хәл итүгә, Россия Федерациясендә граждан җәмгыятен үстерүгә юнәлдерелгән эшчәнлекне гамәлгә ашыручы коммерциясез оешмалар, шулай ук күрсәтелгән федераль законда каралган эшчәнлек төрләре;

социаль хезмәт күрсәтү - халыкка социаль хезмәтләр күрсәтүгә юнәлдерелгән дәүләт һәм ведомство максатчан программалары кысаларында бюджет акчалары исәбеннән күрсәтелә торган хезмәт, шул исәптән дәүләт хезмәтләренең, эшләрнең ведомство исемлекләренә кертелгән (алга таба - хезмәт күрсәтү).

3. Бюджет акчалары исәбеннән хезмәтләр күрсәтү турында социаль юнәлешле коммерциясез оешмалар эшчәнлегенең нәтиҗәлелеге түбәндәге критерийлар белән бәяләнә:

план күрсәткечләрен формалаштырганда билгеләнгән күләмнең мөмкин булган тайпылышларын исәпкә алып, бюджет акчалары исәбеннән күрсәтелә торган хезмәтләр күләме күрсәткечләренең план күрсәткечләренә ирешү;

фактта күрсәтелгән хезмәтләр сыйфаты сыйфатның расланган стандартларына (сыйфат стандартлары расланган хезмәтләргә карата) туры килү.

4. Бюджет акчалары исәбеннән хезмәт күрсәтүче социаль юнәлешле коммерциясез оешмалар эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген бәяләү, аларны күрсәтүнең сыйфатын бәяләү критерийлары Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2009 елның 30 июнендәге «Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре күрсәтә торган дәүләт хезмәтләре сыйфатының билгеләнгән стандартларына туры килүен бәяләүне уздыру тәртибе турында» 446 номерлы карары белән расланган тәртиптә гамәлгә ашырыла.

5. Социаль юнәлешле коммерциясез оешмаларның нәтиҗәлелеген бәяләү критерийларының план билгеләре социаль юнәлешле коммерциясез оешмаларга социаль өлкәдә эшчәнлек башкаруны әлеге программалар кысаларында гамәлгә ашырыла торган хезмәтләр күрсәтүгә шартнамә (килешү) составында максатчан программалар кысаларында бюджет акчалары исәбеннән тапшыручы Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Башкарма комитетының территориаль үсеш бүлеге тарафыннан билгеләнә.

6. Хисап елы нәтиҗәләре буенча социаль юнәлешле коммерциясез оешмалар Башкарма комитетның территориаль үсеш бүлегенә Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы раслаган рәвештә, хисап елыннан соң килүче елның 20 гыйнварына кадәр әлеге Тәртипнең 3 пунктында күрсәтелгән эшчәнлекне бәяләү критерийларының план күрсәткечләренә ирешү турында хисап җибәрә.

7. Башкарма комитетның территориаль бүлеге «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Татарстан Республикасы икътисадый һәм социаль тикшеренүләр үзәге» дәүләт бюджет учреждениесенә

әлеге Тәртипнең 3 пунктында күрсәтелгән социаль юнәлешле коммерциясез оешмалар эшчәнлеген бәяләү критерийларының план күрсәткечләренә ирешү турында җыелма хисапны Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы раслаган рәвештә, хисап чорыннан соң килгән елның 1 февральгә кадәр җибәрә.